Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFƟNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№15 (66)

8 май 2013 ел



## Бөек Җиңү көне белән!!!

***Бөек Ватан сугышы ветераннарын, укытучыларны, хезмәткәрләрне, студентларны, бөтен коллективыбызны Бөек Җиңү көне белән чын күңелдән тәбрик итәм!***

*Бу шатлыклы һәм тетрәндергеч бәйрәм илебез тарихы һәм аның халкы язмышына мәңгелеккә уелган. Без Ватан азатлыгы хакына гомерләрен аямыйча сугышкан каһарманнар алдында бурычлы. Халкыбызның тиңсез батырлыгы, аның тәвәккәллеге, кыюлыгы бүген дә күңелдә тарихыбыз өчен горурлык хисе уята, илебезнең алга таба үсеше өчен ышанычлы нигез булып тора. Туган илебез фашист басып алучыларының төп һөҗүмен үзенә алды, авыр сынаулар аша үтеп, дошманны тар-мар итте һәм башка халыкларга ирек алып килде. Шуңа күрә Азатлык көнен безнең белән бергә башка бик күп илләрдә дә бәйрәм итәләр.*

*Җиңүгә ирешү юлында Казан университеты коллективы да лаеклы өлеш кертте. 1941 елның ахырында ук инде студентларның өчтән икесе һәм укытучыларның яртысыннан күбрәге фронт сызыгында булды. Алар каһарманлык һәм фидакарьлек үрнәге күрсәтте. Әмма барысына да кире әйләнеп кайту насыйп булмады. Без һәлак булганнарга баш иябез. Тылда калганнар Җиңүне киеренке хезмәте һәм фәнни иҗаты белән якынайтты. Яшь буын үзенең җиңүчеләр варислары булуын яхшы белергә һәм истә тотарга, өлкән буынның гомерләре бәрабәренә саклап калган бөек патриотик идеалларына тугры булып калырга тиеш. Бүгенге вәзгыятьтә болар барысы да университетыбызның федераль әһәмияте артуга, илебез тарафыннан билгеләнгән «акыллы икътисад» булдыру бурычын тормышка ашыруга бик нык булыша.*

*Данлы җиңүнең 68нче елын каршылау уңаеннан ветераннарыбызга чын күңелдән саулык һәм иминлек, хәзерге вакытта университетта эшләүче һәм белем алучыларга яңа үрләр һәм тыныч аяз күк йөзе телим.*

**Ректор Илшат Гафуров**



Алия Галимуллина фотосы

# Яңарышлар ныклы нигездә

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кичә, ягъни 7 май көнне, КФУның Идарә һәм территориаль үсеш институтының Актлар залында сугыш һәм тыл ветераннарын котлау тантанасы узды. Чара Бөек Җиңүнең 68 еллыгына багышланды.

Һич онытырга мөмкин булмаган изге тарихи Җиңүдән соң 68 ел узып та киткән. Безнең өчен бик изге булган әлеге дата ветераннарыбыз хәтерендә үткәннәрне бүген булган кебек хәтерләрендә яңара. Тантанага гомерләрен университетта белем бирүгә багышлаган, хәзер инде лаеклы ялда булган сугыш һәм тыл ветераннары чакырылды. Алар өчен сыйга бай матур өстәлләр һәм концерт номерлары әзерләнгән иде. Җиңүгә юл озын һәм авыр булды. Сугышның һәр көне ветераннар күңеленә кан һәм үлем, кайгы һәм ачы югалту, зур һәм кечкенә җиңү шатлыгы булып уелган.

КФУ ректоры Илшат Гафуров ветераннарны әлеге бөек бәйрәм белән котлады. «Хезмәтегез, барлык эшләгән эшләрегез өчен рәхмәт Сезгә. Күбегезнең балалары да гомерләрен белем бирү системасына багышлады. Монысы өчен дә без Сезнең алда бурычлы. Бер ел эчендә университетыбыз тормышы бик тиз темплар белән үзгәрде. Яңа биналар төзелде. Июнь аенда планетарий ачылачак. Бу яңарышларның һәммәсе бүген эшләнә, әмма алар Совет заманнарында һәм үзгәртеп кору елларында Сез эшләп калдырган ныклы нигезгә таяна. Безнең өчен киңәшләрегез дә, тәнкыйтегез дә бик мөһим. Аларны ишетергә без һәрвакыт әзер. Сезгә ныклы сәламәтлек, балалар һәм оныклар бәхете телим! Якыннарыгыз һәрвакыт янәшәгездә булсын, Сезгә күз яше китермәсен», – дигән теләк белдерде ул чыгышында. Ректор ветераннарга шушы көннәрдә университетыбызның Алабуга институтына кунакка килгән Санкт-Петербург университеты делегациясенең кайнар котлавын да җиткерде.

Тантанада Бөек Ватан сугышы ветераннары советы җитәкчесе Рәфкать Таһиров та катнашты. «Мин үзем яшь фронтовиклардан саналам, чөнки сугышның икенче яртысында гына фронтка киттем. Безгә кадәр сугышканнар иң авыр сынауларны кичерде. Алар алдында баш иябез. Без инде күбесенчә һөҗүм иттек. Бу вакытта үзебезне җиңүче итеп тойдык һәм әлеге хис безгә Җиңүне якынайтуда көч өстәп торды», – диде ул.

Чараны КФУның «Хор капелласы» башкаруындагы сугыш турындагы җырлар, укытучылар һәм студентлар әзерләгән башка концерт номерлары бизәде.

**• Хезмәттәшлек**

# КФУ төп партнерлар исемлегендә

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

6 май көнне ректорат утырышлары залында Казан федераль университеты һәм Страсбург университеты арасында халыкара хезмәттәшлек турындагы өстәмә килешүгә кул куелды.

Очрашу барышында ике як вәкилләре дә үзара партнерлыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында сөйләште. КФУ ректоры Илшат Гафуров Страсбург университеты белән хезмәттәшлекнең унъеллыгы турында әйтеп узды һәм бу багланышларның киләчәктә дә нәтиҗәле үстерелүенә өмет белдерде. Ректор француз хезмәттәшләренә хемоинформатика буенча магистр программасын үстерүгә булышлык күрсәткәннәре өчен рәхмәтен белдерде.

Ахыры 2нче биттә.



КФУ матбугат үзәге фотосы

## • Вакыйгалар эзеннән

**КФУ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру буенча **КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ** (Түбән Новгород өлкәсе) **УТЫРЫШЫНДА КАТНАШТЫ**. Делегация составында Мәгариф ресурсларын үстерү департаменты директоры Галина Ившина, география һәм картография кафедрасы доценты Рамил Динмөхәммәтов, социаль яклауны оештыру һәм эшкә урнашканда булышлык күрсәтү бүлегенең югары категорияле белгече Любовь Павлова бар иде. Фикер алышуның темасы – «РОСАТОМ» дәүләт корпорациясе предприятиеләренең яшь белгечләрне барлау, югары һәм урта белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру буенча эшләү тәҗрибәсе».

• • • •

**29 АПРЕЛЬ** көнне ТР Фәннәр академиясендә КФУ ректоры, икътисад фәннәре докторы, профессор Илшат Гафуровның **«КОНКУРЕНТЛЫККА СӘЛӘТЛЕЛЕК ҺӘМ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕҢ КОНКУРЕНТЛЫ СТРАТЕГИЯСЕ»** темасына ачык лекциясе булды. Сайлап алынган тема И.Гафуровның фәнни эшчәнлеге нигезен тәшкил итә. Шунда ук Казан университетының ТР Фәннәр академиясе белән алга таба да хезмәттәшлек итәчәге ачыкланды һәм килешүгә кул куелды.

• • • •

Шушы көннәрдә ФСИның сәнгать бүлегендә итальян композиторы, мультиинструменталист, пианист-импровизатор **МЕЛО МАФАЛИ** белән **ОЧРАШУ БУЛДЫ**. Маэстро барокко, импрессионизм, америка ритм-н-блюзы, Б.Барток, Р.Яхин стильләренә якын килеп, берничә төрле импровизация башкарды, студентлар һәм укытучыларга импровизация сәнгатенең кайбер серләрен чиште һәм аларның сорауларына җавап бирде.

• • • •

**29 АПРЕЛЬДӘ** Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында Сассари университеты (Италия) профессоры **ВИНСЕНЗО ПАСКУЧЧИ** «Киләчәкне танып белү ачкычы буларак палеоклимат: Урта диңгез бассейны мисалында» темасына **ЛЕКЦИЯ УКЫДЫ**. Аның визитының төп максаты – 2017 елда булачак Халыкара конгрессны үткәрү өчен шәһәр билгеләү. Хәзерге вакытта галим Казан һәм Санкт-Петербург шәһәрләренә тукталганын әйтте.

• • • •

**4 МАЙДА** студентларның Бөек Җиңүнең 68 еллыгына һәм Сталинград сугышының 70 еллыгына багышланган **Х ХАЛЫКАРА ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКА ЙӨГЕРЕШЕ СТАРТ АЛДЫ**. Беренче көнне үк йөгерештә катнашучылар сафына Удмуртия һәм Татарстан чигендә КФУның Алабуга институты студентлары кушылды. Марафончылар бергәләп Алабугага кадәр йөгерде һәм Мәңгелек ут һәйкәленә чәчәк салды. Әлеге җиңел атлетика эстафетасы 8 май көнне Минскида тәмамланачак.

• • • •

Күптән түгел КФУның Яр Чаллы институтында Нидерландтан килгән медицина профессоры **ЯН ВИЛЛЕМ ДЕ ВОСА АЧЫК ЛЕКЦИЯ УЗДЫРДЫ**. Лекция кешенең алкоголь һәм наркотикларга бәйлелеге мәсьәләсенә багышланган иде.

• • • •

**7 МАЙ** көнне **КФУ**ның **ГЫЙЛЬМИ СОВЕТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Утырыш башланганчы, ректор **И.Гафуров** Филология һәм сәнгать институтының француз филологиясе кафедрасы җитәкчесе **В.Н.Васильевага** «ТР югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре» дигән мактаулы исем алу турында таныклык һәм күкрәк билгесе тапшырды. Шулай ук Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының социология кафедрасы профессоры **К.Н.Новиковага** ТР президентының рәхмәт хаты бирелде.

Утырышны Гыйльми Совет рәисе, ректор **И.Гафуров** ачып җибәрде, көн тәртибенә куелган дүрт мәсьәлә белән таныштырды. Беренче булып, кафедра җитәкчеләре сайланды. Икенче мәсьәлә буенча да профессор, өлкән укытучы, укытучы вазифаларына сайлау узды. Өченче өлештә профессор, доцент дәрәҗәләрен бирү каралды. Алар турында мәгълүматны Гыйльми Советның гыйльми сәркатибе, профессор **М.Д.Щелкунов** җиткерде. Соңгы өлештә кайбер кафедраларның исемен алыштыру, яңа бакалавр һәм магистр программаларын ачу, шулай ук уку йорты галимнәренә төрле мактаулы исемнәр бирү мәсьәләләре каралды.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## • Мөнбәр

# Йөрәктә бөреләнгән гамәлләр

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче



IV РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ УЗДЫРЫЛГАН ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ УКЫТУЧЫЛАРЫН БАРЛАУ БӘЙГЕСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА, ИҢ ЯХШЫ УКЫТУЧЫЛАР ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА УКЫТА ИКӘН!

Әлеге бәйгедә катнашу өчен, 36 укытучы гариза биргән һәм аларның 10сы гына финал өлешенә узган. Анда остазларыбыз «Мин һәм минем профессиям» темасына иҗади презентация һәм дәрестән өзек күрсәттеләр. «Гуманитар фәннәр буенча иң яхшы укытучы» номинациясендә I урынга – Кече ФСИның сәнгать бүлеге деканы, сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты, педагогик фәннәр кандидаты Мәдинә Мәхмүтова, III урынга шулай ук Кече ФСИның татар филологиясе бүлеге деканы, XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Гөлфия Гайнуллина лаек дип табылды.

Мәдинә Мәхмүтованың педагогик осталык сәләте ерактан ук килә. Аның нәселендә укытучылык һөнәрен инде дүртенче буын вәкилләре дәвам итә. Мөгалимә Идел буе халыкларының милли традицияләрен өйрәнә, үзенең фәнни һәм иҗади эшчәнлеген дә шуңа багышлый. Бәйгедә дә ул «Идел буе халыкларының милли костюмнарын стилизацияләү һәм модельләштерү (XIX – XX гасыр башы Казан татарлары костюмнары мисалында)» темасына дәрес фрагменты күрсәтеп җиңүгә ирешә. «Бу уңыш – бөтен коллективыбызның уңышы. Хезмәттәшләр, студентларың ярдәмен тоеп тору һәм иҗади үсеш өчен университет җитәкчелеге булдырган шартлар – үзе үк җиңүгә стимул булып тора!» – диде Мәдинә Мәхмүтова.

Югары профессионализм планкасын тоту җиңел эш түгел, ләкин Гөлфия Расил кызы да мондый дәрәҗәгә лаек икәнен инде күптән дәлилләгән иде. Аның хезмәтендә иң бәхетле вакыты – студентларга дәрес бирү вакыты икән. Студентларны шәхес булырга өйрәтү, татарның бөек шәхесләре әйтеп калдырган хакыйкатьне җиткерү, милләтебезгә хезмәт итәргә әзерләү мөмкинлеге бирелгәнгә ул үзен чиксез бәхетле дип саный.

«Ә.Еникинең повестьларын өйрәткәндә, кешегә табигать тарафыннан бәхетле булу мөмкинлеге бирелгән, көч салынган, ләкин әлеге потенциалны эшкә җигәргә комачалаучы җимергеч көч тә бар, дигән фикерне табабыз. «Рәшә» повестенда олуг әдип курку хисе – кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, ди. Күңелендә курку хисе йөрткәннәр матди һәм рухи бәйсезлеккә ирешә алмый, үзләре туплаган малның колына әверелә, дигән хакыйкатьне җиткерә. Курку хисен иманга килү – тормышка, милләтеңә мәхәббәтне тану гына җиңә ала.

Хезмәтеңне, милләтеңне чын ихластан ярату бервакытта да җавап хис таләп итми, милләтеңнән җавап хис сорап өзгәләнү, сине яратуларын, тануларын көтү – ул, минем балам кайчан миңа игелек эшли башлар икән, дип көтеп утыру кебек мәгънәсезлек. Милләткә карата кылган гамәлләр йөрәктә бөреләнә».

Укытучының мөгаллимлек хезмәтендә икенче зур юнәлеш барлыкка килде. Ул – институтыбызга, бүлегебезгә сәләтле, максатчан татар балаларын туплау. «Минем максат бер генә – гыйлемгә омтылышлы татар балалары Филология һәм сәнгать институтында канат ныгытып, төрле өлкәләрдә милләтебезгә хезмәт итсеннәр иде. Татар кешесенең бәхетле булу юлы – борынгыны олылап, үз буыны алдында лаеклы һәм җаваплы гамәл башкара алу», дип әйтә укытучы, ә күңеленнән зурракка өметләнә.

Гөлфия Расиловна кешеләрдә ихласлыкны, горуртыйнак эшлеклелекне ихтирам итә. «Кешелек горурлыгы – үзеңә салынган көчне юкка исраф итмичә тиешле гамәлләр кылып яши белү ул. Ә.Еникинең Рәшидәсе әйткән хакыйкатьне студентларыма сеңдерергә телим: «Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!»

Тормышының тәртибе Күкләр тарафыннан билгеләнгән гамәлләрне үз көенә, кабаланмыйча башкаруда дип күрә ул. Рухи әзерлеге җиткән вакытка олуг шәхесләребез турында зуррак аудиториягә сүз ирештерергә дип язмыш юл сызса, татар һәм рус телләрендә хезмәт язарга исәбе бар икән.

«Минем өчен бер канун ачык – кеше тормышының мәгънәсе – рухи камиллеккә омтылу, кылган гамәлләреңне шул омтылыш белән үлчәү, үлем ноктасыннан бәяләү».

Мөгалимәләребезнең бу җиңүләре соңгысы булмас, дип өметләнәбез. Аларга эшләрендә сабырлык һәм рәхмәтле студентлары күп булсын иде дип телибез!

## • Хезмәттәшлек

# КФУ төп партнерлар исемлегендә

**Башы 1нче биттә.**

Очрашуда КФУ ягыннан фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев, тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов, Химия институты директоры Владимир Галкин, органик химия кафедрасы җитәкчесе Игорь Антипин, шул ук кафедраның кече хезмәткәре Тимур Мәдҗидов та катнашты. Страсбург университетының химия факультеты директоры Жан-Марк Плане, үз чиратында, университет җитәкчелеген кунакчыл булулары өчен рәхмәт әйтте.

Страсбург университеты 2009 елда үзгәрешләр кичерә. Нәтиҗәдә халыкрара бәйләнешләргә да зур игътибар бирелә башлый. Жан-марк Плане белдергәнчә, бүген Казан университеты төп партнерлар исемлегендә. Сөйләшүләрдән соң, өстәмә килешү һәм хемоинформатика буенча икеләтә диплом программасын булдыру турындагы протоколга кул кую тантанасы булды. Документларга Страсбург университетының химия факультеты директоры Жан-Марк Плане һәм КФУның А.М.Бутлеров ис. Химия институты директоры Владимир Галкин имза куйды.

Кичә Бутлеров аудиториясендә «Франциядә химия буенча белем бирү» дигән темага лекция уздырылды. Биредә супермолекуляр химия өлкәсенә караган мәсьәләләр хакында фикер алышу булды.

# Дуслык җепләре ныгый



6 МАЙ КӨННЕ АЛАБУГА ИНСТИТУТЫНДА «БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА ӨЧ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫНЫҢ ҮЗАРА ДУСЛЫГЫ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ.

Чарада Санкт-Петербург университеты, КФУның тарих институты, Алабуга институты, Алабуга дәүләт тарихи-архитектур музей-тыюлык вәкилләре катнашты. Чараны ректор Илшат Гафуров ачып җибәрде: «Җиңү сугыш кырында гына түгел, тылда да булган: кемдер фән белән шөгыльләнгән, кемдер заводларда эшләгән».

Конференция тәмамланганнан соң, Ленинград һәм Воронеж дәүләт университетларының 1941-1944 елларда Алабугада эшләгән галимнәренә багышлап мемориаль такта ачтылар. Ул Бөек Ватан сугышы чорында өч уку йортының дуслык җепләре ни дәрәҗәдә нык булганы турында сөйли. Такта өченче катның рекреацион залында урнаштырылды.



Чара Казан федераль университеты һәм Санкт-Петербург дәүләт университеты арасында хезмәттәшлек килешүенә кул кую белән тәмамланды. Әлеге килешү кысаларында фәнни-тикшеренү һәм уку-укыту эшчәнлеге буенча хезмәттәшлек итү планлаштырыла.

*Өстәге рәсемдә: Санкт-Петербург дәүләт университеты проректоры Сергей Туник.* КФУның Алабуга институты матбугат үзәге фотолары

● Бөек Җиңү көне

# Университет - Бөек Ватан сугышы чорында

Казан университеты тарихын көнендә яңарткан, Бөек Ватан сугышының фаҗигале көннәренә аеруча нык тукталмыйча мөмкин түгел.

Ачы сугыш җиле әлеге уку йорты тормышының да үзәгенә үтеп керә. Сугышның беренче айларында университет тәмам бушап кала. Ир-атларның барысы да – профессорлар, укытучылар һәм студентлар фронтка китә. Ә нинди дер сәбәп белән сугышка китми калганнарны, студентларны һәм укытучы хатын-кызларны кырык беренче елның яңгырлы-бозлы салкын көзендә Идел буена кәйлә, көрәк белән оборона сызыгын казу эшенә җибәрәләр. Студент группаларында нибарысы 7-8әр кыз укый. Шушы фаҗигале көннәр хакында соңыннан 1933 елдан бирле СССР геологиясе кафедрасын җитәкләгән күренекле геолог, геология-минералогия фәннәре докторы, профессор Евгения Ивановна Тихвинская (1901-1976) истәлекләр китабы яза.

Сугыш чоры турында фронтовик, озак еллар Казан университетында эшләгән, физика-математика фәннәре докторы Рәфгат Бикмулла улы Таһиров та шулай ук бик кызыклы документаль китап иҗат итә.

Казан Ватан сугышы елларында тыл шәһәре була. Уку йорты үзенә СССР ФАнең башлыча физика-химия юнәлешендәге 33 гыйльми оешмасын кабул итә. Чынлыкта, илнең Фәннәр академиясе тулысынча Казан университетында торып эш итә. Мондагы тарих музеенда СССР ФА фәнни-тикшеренү институтлары директорларының, исемнәре бөтен дөньяга билгеле галимнәрнең бергәләп төшкән бер фоторәсеме кадерләп саклана. Әлеге музей шушы һәм башка галимнәрнең шәхси әйберләрен, аларга бәйле экспонатларны туплауда зур эш башкарды. Игътибарны мондагы бер кызыклы экспонатка юнәлдерәсе килә. Ул – моллюскалардан ясалып киптерелгән шашлык. Сугыш чорында академиклар аларны Казансу елгасында тотып, әнә шулай утта кыздырып ашаганнар. Бу галимнәрнең төп туклану ризыгыннан берсе булган. Бәхәссез ки, башкаладагы төп фәнни-тикшеренү институтларының вакытлыча Казан университетында урнашуы һәм бөтен дөньяга танылган галимнәрнең биздә эшләве тарихта уңай эз калдыра, фән үсешенә көчле этәргеч ясый.

Тыныч хезмәтне сагынып, уку йортына әйләнеп кайткан укытучылар җиң сызганып эшкә тотыналар, фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнеп, диссертацияләр яклап, галим булып китәләр. Бөек Ватан сугышы юлларын аркылыга да, буйга да иңләгән күренекле астроном, физика-математика фәннәре докторы, профессор Шәүкәт Таил улы Хәбибуллин (1915-1996) университет тарихында якты эз калдыра. Ул 1948 елда, хәрби хезмәттән кайтуга, университетта эшли башлый. 10 ел чамасы В.П.Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясенең Айны өйрәнү бүлеген, озак вакыт дәвамында астрономия кафедрасын җитәкли. Михаил Тихон улы Нужин да «беренче сәгатеннән алып соңгы сәгатенә кадәр» сугышта була. Ә инде сугыштан соң физика-математика фәннәре докторы, профессор Нужин чирек гасыр буе ректор булып эшли.

Олуг галим-этнограф, географ, тарихчы, тарих фәннәре докторы, профессор Евгений Прокопьий улы Бусыгин да (1914) үзенең чәчәктәй яшьлек еллары һәм сәламәтлеген Ватан сугышына бирә. Сугыштан ул 1949 елда туп-туры уку йортына кайтып төшә һәм алты дистәгә якын гомерен гыйльми эшкә, этнографиягә һәм студентларны укытуга багышлый. Күп еллар дәвамында этнография кафедрасы мөдире була. Ул бүген дә университетта киңәшче хезмәтен үти.



Е.П.Бусыгин башта музыкант була. Опера театры оркестрында бик оста итеп скрипкада уйный. Соңга таба аңа фәнни тикшеренүләр җене кагыла. Ул бөтен сугыш еллары буена скрипкасын үзеннән калдырмый, иң кыен минутларда шул уен коралында уйнап, сугышчан дусларының кәефен күтәрә, кайгысын уртаклаша. Фронтовик үзе өчен бик тә кадерле әлеге скрипканы музейга бүләк итә. Әйе, талантлы кеше кайда да талант иясе булып кала. Бу җәһәттән исеме бөтен дөньяга билгеле академик А.Е.Арбузовның да КДУ квартетында уйнавын тагын бер мәртәбә искә төшерик.

Төп бинаның беренче катында сугыш кырларында ятып калган университет хезмәткәрләренә һәм студентларына багышланган почмак бар. Кара мәрмәргә аларның исем-фамилияләре уеп язылган. «Ватаныбыз азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен сугышта һәлак булганнарга мәңгелек дан».

*Мәгълүмат Ягъсуф Шәфыйковның «Казан университеты» китабыннан алынды.*

● Тарих эзләреннән




**Бөек Ватан сугышы** елларында университет студентлары квч танкын төзү өчен 106565 сум акча җыя. Бу гамәл өчен И.Сталин Кызыл Армия исеменнән Казан университеты ректоры К.П.Ситниковка Рәхмәт хаты җибәрә.

**23 июньдә** Казан университетының актлар залында студентлар, фәнни хезмәткәрләр, эшчеләр Молотовның 1941 елның 22 июнендә СССРга немец гаскәрләре бәреп керүе хакындагы хәбәре уңаеннан митинг уздыра. Чара барышында университет проректоры В.Т.Макаров студентларны һәм профессор-укытучылар коллективын совет халкының бердәм омтылышына кушылырга һәм туган илне фашист һөҗүменнән сакларга чакыра. Митингта профессор Б.А.Арбузов та катнаша. «Дөнья тарихында яңа бит ачылды. Без ватаныбызны саклап калу өчен барлык көчебезне һәм белемебезне, кирәк булса гомеребезне дә кызганмаячакбыз!» – дип белдерә. Чарада Молотов стипендиаты Шестаков һәм чыгарылыш курс студенты Ворошилов та үз сүзләрен әйтә. Соңгысы укытучыларны тагын да нәтиҗәле фәнни хезмәткә, ә студентларны җәйге ялларда эшкә чыгарга чакыра.

**1967 елда** университетның география факультетында беренче «Кар десанты» оештырыла. 70-80 елларда бу хәрәкәт бөтен факультетларны колачлый һәм бик тиз арада хәрби-патриотик рухлы агымга әйләнә. Алар Бөек Ватан сугышы тарихын, сугыш елларында Идел буе территориясендә оешкан частьларның һәм берләшмәләрнең хәрби походлар юлларын өйрәнә, сугыш ветераннары һәм шаһитлары белән очрашулар оештыра, хәбәрсез югалганнарны эзләү эшләрен башкара.

**1991 елның сентябрендә** Казанның Мәскәү районында урнашкан 122 мәктәпнең югары сыйныф укучылары янәдән «Кар десанты» оештыра. Аны Казан дәүләт университетының тарих факультеты укытучылары, «Кар десанты» элеккеге көрәшчеләре җитәкли. Отряд эшчәнлеге яңа юнәлешләр белән баетыла: Үлем үзәнендә (Долина смерти) яңа экспедицияләр оештыру, республиканың «Хәтер Китабы»н төзүдә, укучы яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүдә катнашу һәм башкалар.

**Бөек Ватан сугышының** иң кызган вакытында Казан университеты студентлары Ананьева, Макарова, Менч, Торопова, Трогикова, Степанов, Степанова, Бахматов Иваново авылы советының «Ударник» колхозында эшли. Алар бирелдә 138 көн буе хезмәт куя.

**1941-1943 елларда** Казан университеты Мәскәү һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән СССРның Фәннәр Академиясе хезмәткәрләре өчен тулай торак вазифасын башкара. Университетның төп бинасында Академиянең президиумы, берничә институт үз эшчәнлеген алып бара.

# Беркем дә онытылмады!

**Кадрия ХӘСӘНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Сугыш... Биш кенә хәрефле әлеге сүзгә күпме сагыш, моң-зар, кайгы, күз яшьләре сыйган. Аналарны ялгыз, хатыннарны тол, балаларны ятим иткән ул. Халкыбыз 1418 көн һәм төн дәвамында дәһшәтле вакыйгалар, моңарчы күрелмәгән язмыш сынавы чолганышында яши. Кайгы җиле бер генә гаиләне дә читләтеп узмый, һәр йорт диярлек сугыш ачысыннан боегып, ямансулап кала.

Апас районыннан Ватан сакларга ут эченә 9112 кеше китә. Әмма күбесенә туган-үскән нигезләренә кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Алар Ватан азатлыгы, Европаны фашизм тырнагыннан коткару өчен изге яуда башларын салып, читят җирләрдә мәңгелеккә ятып калалар. Ләкин ул куркыныч вакыйгаларның тере шаһитлары – исән-сау әйләнеп кайтучылар да бар әле! Әмма ни кызганыч, аларның сафлары көннән-көн кими. Безгә җиңү алып кайткан, аяз күк йөзен, тыныч тормышны яулап алучан каһарманнарыбыз алдында без мәңгегә бурычлы. Күршебездә яшәүче Хәбибрахман Мөхәммәтзакир улы Закиров әнә шундыйлардан иде...

Ул 1919 елның 12 августында Апас районы Кече Болгаер авылында дөньяга килә. Гаиләләрендә балалар бик күп була. Чөнки әтисенең ике хатыны да үлә – ул сигез бала белән ялгыз кала. Һәм янадан өйләнә, бу гаиләдә тагын сигез бала туа. Иң олысы – Хәбибрахман бабай. Ул 16 яшендә Мәскәүгә киткән җиреннән сугышка алына. Аның энесе Кәбир дә сугышка китә, тик ул яу кырыннан әйләнеп кайтмый. Хәбибрахман бабай башта бер шәһәр оборонасында тора. Сугышта өч тапкыр яралана. Польшада аякларын пуля кисеп чыга. Кулибяко шәһәрендә өч ай госпитальдә ята. Аннан соң тагын сугышка... Җирдән үрмәләп барганда, аңа икенче тапкыр пуля эләгә. 1945 елда аны кырдан табып алалар. Аяклырындагы җәрәхәттән кан итекләре тулы кан була. Марттан алып, октябрь ахырына кадәр ул янә госпитальдә ята. Туган авылына әйләнеп кайтырга насыйп була аңа. Тик 25 елдан соң сугыш яралары тагын яңара әле – аягыннан тимер кыйпылчыгы алалар.



Сугыштан соң Хәбибрахман бабай авылда кырчылык бригадиры булып эшли. Эшкә йөргәч колхоз ат бирә. Шушы ук авыл кызы Зәйнәпкә өйләнә. 1960 елда өй торгызалар. Аларның алты балалары туа. Тик берсе, ул вакытларда бик күп сабыйлар кебек, кызамык авыруыннан үлә. «32 ел кайнана белән яшәдек. Өйдә әле Хәбибрахманның ике сеңлесе дә бар иде. Аллаһка шөкер, бик әйбәт яшәдек», – ди Зәйнәп әби.

Ул да сугыш еллары шаһиты. Гаиләләрендә 8 бала булалар. Иң авыр вакытларда биш ел тракторист булып эшләгән. Кырда куныл калган чаклары да күп булган. Төнлә урман эченнән дезертирлар чыгар, дип курка торган була хатын-кызлар. «Җимерек күперләрдән, ермак кырыйларыннан йөри идек, Ходай гомер биргәч, исән-сау калдык инде», – дип сөйли Зәйнәп әби. Ул вакытта тамакка да каты-коты бит инде. Хатын-кыз болай да көчсез зат, әле тимер тракторны да иярләргә кирәк. Черек бәрәңгене уып, ипи, чөгендер яфрагыннан аш пешергәннәр. «1992 елда машина бирделәр. Дәүләт онытмый. Пенсия бирәләр. Бәйрәм саен күчтәнәчләр өләшәләр. Без бик риза», – ди тыл ветераны.

Кызганыч, Хәбибрахман бабай күптән түгел гүр иясе булды. Урыны җәннәттә булсын! Зәйнәп әби игезләү яшәсә дә, янына балалары кайтып тора. Бүген аның сигез оныгы, биш оныкчыгы бар. Изге теләктә, догада яши ята Зәйнәп әби.

● «Илһамлы каләм»



26 апрель көнне Филология һәм сәнгать институтында «Илһамлы каләм» V Бөтенроссия әдәби әсәрләр конкурсының йомгаклау тантанасы узды. Конкурсның беренче турына 250дән артык эш кабул ителде. Шулар арасыннан 40 катнашучы, икенче турга узып, тагын бер кат каләменең үткенлеген сынады. Быелгы конкурста катнашып, аеруча уңышка ирешкән яшь каләмчеләрнең иҗатын сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.



## Гран-при иясе –

**Гөлнур ШӘРИПОВА** - Балтач районы Борбаш мәктәбенең 11 сыйныф укучысы

# Тукайга

*Үрнәк алып бары синнән генә,*
*Аяк бастым шигърият иленә.*
*Кереп киттем синең әсәрләрең аша*
*Хыялымның иң серле түренә.*

*Шигырьләрең – матур сукмаклардыр;*
*Әкиятләрең – гүя урманнар.*
*Әз түгелдер шул сукмаклар буйлап*
*Урманыңа кереп калганнар.*

*Һәр язылган сүзең, минем өчен,*
*Шул урманда кошлар сайравы.*
*Ул кошларның сихри җыр-моңнарын*
*Бер дә кыен түгел аңлавы...*

*Синең иҗатыңнан илһам алып,*
*Шигъри юллар үрәм берәм-берәм.*
*Күңелем белән сиңа якынаеп,*
*Даһи Тукай, сине үрнәк күрәм!*

## «Иң яхшы шигъри әсәр» номинациясе

**Илзия ФӘЙЗЕРАХМАНОВА** – Балтач районы Куныр мәктәбе

***

*Кеше, күбрәк сынау күргән саен,*
*Сыгылмаска бары тырыша.*
*Тормыш буранында йөргән саен,*
*Ике юл чатында адаша.*

*Йөрәк сызлый, әрни, ул яна...*
*Күрми башлый барыр юлларны.*
*Күз алдына килә үткән тормыш,*
*Искә төшерә узган елларны...*

*Батыр кеше генә тора ала.*
*Сынса, сыгылса да торачак!*
*Бураннарда күңел күзе белән*
*Туры юлны да ул табачак.*

*Шуңа күрә яшьтән бирешмик без,*
*Сынауларны атлап чыгарбыз.*
*Алда әле безнең яшь чакларны*
*Гөрләтеп яшисе чагыбыз.*

## «Иң яхшы чәчмә әсәр» номинациясе

**Илсинә ГАРИПОВА** – Саба районы Байлар Сабасы гимназиясе

# САГЫШЛЫ ҖӘЙ

Бар җиһан тирән йокыда. Бары Хәтимә әби генә зур түземсезлек белән таң атканын көтеп утыра. Кытыршы нәзек куллары белән газизе Илфат язган хатларны актара. Бусы – соңгысы, ун ел элек язылган. Кайтсам, тауларга менәр идем, синең тәмле ашларыңны туйганчы чөмереп куяр идем, дигәнме? Кайткан булсамы, өрмәгән урынга да утыртмас иде әнкәсе, кайтмады шул, кайтмады... Ут эченнән чыгарга насыйп булмады. Шуларны уйлап, Хәтимә әбинең күзләре яшьләнде. Кан басымыннан фельдшер эчәргә кушкан даруын капты да бәрәңге бакчасына чыкты. Сагыш тулы күзләр бер ноктага текәлде, ялгыз ана хатирәләргә күмелде.

Ун ел инде ана улын көтеп яши. Әйтерсең, Илфаты шушы бәрәңге бакчасыннан кызукызу килер дә көтү сагышыннан кечерәеп калган Хәтимәне кайнар кочагына алыр. Ничә еллар карчык кеше, хәле булмаса да, бакча печәнен чаба, янәсе, улы кайта калса, аяклары чыланмасын, көткәнен күреп шатлансын. Сагынды, бик сагынды ул сабыен, тик кайту язмаган икән.

1984 нче ел. Илфат әнисенә бүтән хат язып тормаска кушып, тиздән үзе кайтып җитәчәген әйтеп хат яза. Сөенечле хәбәр! Тик хаттагы кайбер җөмләләр ананың күңелен шул вакытта ук тетрәндерә. Күз алдына шәрә таш кыялары, комлы чүлләр өстендә аунап яткан япь-яшь егет гәүдәләре килеп баса. Әчегән ризыклардан күңелләре болай да болганган солдатлар атышка бара. Мәҗбүри рәвештә. Син уйламаганда, ядрә сибелә башлый. Кем-кемгә атканын да аңлап булмый, чөнки «ядрә яңгыры»ннан башка берни дә күренми. Шунда, ялгыш, таныш-белешкә дә, хәтта дустыңа да эләгә. Йә син, йә ул уеннан чыгарга тиеш. Кешене үтерү күңелендә дә булмаган егетләр ерткычка әверелә. Хаттан аңлашылганча, моның Илфаты да элеккеге Илфат түгел. Олы йөрәген боз йөрәккә әйләндергән түгелме Әфганстан?!

Кинәт капка ачылды. Хәрби киемдәге кешеләрне күргәч, ананың йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Тик ул үзүзен алдарга, тынычландырырга ашыкты. Болары дуслардыр, әллә командирлары микән? Тавыкларын ашатырга чыккан Хәтимәнең кулыннан кәстрүле төшеп китте. Озынрак хәрби кеше катып калган ананы кочагына алып кысты. Ана еларга да, кычкырырга да белмәде. Сорамакчы иде дә, бугазына авыр төер утырды. Нигә мине йөрәк парәм кочакламый, мин бит аны сагындым, минем бит аны күрәсем килә, кайда ул, дигән борчулы сораулар башына яшендәй сукты, күз алды караңгыланды. Берни дә дәшергә кыймаган хәрбиләр ананы култыклап өйгә алып керделәр.

- Мин бит аны чүлдә ятып калсын дип үстермәдем. Кайтарсыннар улымны, ничек җибәрдем, нәкъ шулай ук кайтарып бирсеннәр, хәшәрәтләр, җир йотсын үзләрен. Минем баламны... Каһәр суккан сугыш!

- Аның гәүдәсе...

Таныш түгел кеше сүзен әйтеп бетерә алмады, башын читкә борды.

- Мин... мин сезгә сау-сәламәт баламны тапшырдым бит, ә сез... миңа гәүдә дип утырасыз. Нишлим мин ул гәүдә белән, нишлим?! Җавап бир!

Хәтимә әби катып калган егетнең якасына ябышты.

- Бердәнбер балам иде бит ул. Аңлыйсыңмы? Кырыкта гына, азаплана-азаплана гына таптым бит мин аны, ә сез... Кайда ул, кайда?

Җавап ала алмагач, ана озын буйлы хәрби алдына тезләнде. Җан өзгеч тавыш белән:

- Мин бит сездән күп әйбер сорамыйм, үз кулларым белән биргән баламны гына кире кайтарыгыз, Алла хакы өчен! Кайтарыгыз аны!

- Бу... мөмкин түгел...

Хәтимә карчык, битен тырный-тырный, үксеп-үксеп елады. Хәрбиләр ишегалдына Илфатның мәетен алып керергә ашыкты. Чөнки вафат булган солдатлар шактый, аларны да якыннарына тапшырасылары бар. Ана табут өстенә ятты:

-Илфатым, жаным, нишләттеләр алар сине?! Бирмим, башкача берегезгә дә бирмим, ишетәсезме, бирми-ииим, балакаем минем! – дигән тавыш бөтен авылга яңгырады. Ананың тавышы карлыкты, күзләре төссезләнде, йөзе агарып катты.

-Ник монда куйдыгыз аны? Ул җәй көне печән өстендә йокларга ярата, ташлы ишегалдына куймагыз, суык тия ич. Бакчада чабылган печәнем бар, йомшакта, хуш истә ятсын. Илфатым, исән-сау әйләнеп кайттыңмы, балам? Атаң гына юк, кайтканыңны күрсә, ул да сөенер иде. Хәзер-хәзер, арт якка алып чыгып яткырам үзеңне, арыгансыңдыр, йоклап ал. Аннары мунча керерсең, син ярата торган себерке дә, компот та әзер. Токмачлы аш кына өлгертә алмадым, мин көткәннән дә иртәрәк кайттың, болай да газапладым әнине дигәнсеңдер инде... Мин аш куям, син ятып тор, бәбкәм. Ә сез, улларым, саклагыз аны, урлап китә күрмәсеннәр нарасыемны!

Хәтимә кәстрүлен алып, йөгерә-йөгерә, өенә кереп китте. Хәрби кешеләр генә тиз арада фельдшерны чакыртырга кирәк, дип сөйләшеп калды.

## «Иң яхшы публицистик әсәр» номинациясе

**Гөлфия ӘХМӘТОВА** – Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе

# Китап - могҗиза

«Үзенең бәхетенә һәм киләчәк куәтенә бару юлында кешелек тудырган барлык могҗизаларның иң катлаулысы һәм бөеге, мөгаен, китаптыр... Китап – безнең өчен җансыз бушлык дөньясыннан хәрәкәтчән тормыш дөньясына карый торган тәрәзә», – дигән бит М.Горький. Китап – кеше хәтере, юлдашчысы, киңәшчесе, ярдәмчесе, укытучысы, китапсыз халык тарихсыз халыкка әйләнә, ә тарихын онытkan халыкның киләчәге өзелә. Китапханә без, укучыларның, төп таяну ноктасы булып тора, безне белемле итүдә зур роль уйный. Белемнең күп өлешен кеше үзлегеннән китаплардан ала. Аның кеше тормышындагы роле әйтеп бетергесез. Ул – кеше куллары һәм акылы белән тудырылган могҗиза. Мөселманнар өчен иң кадерле китап – Коръән. Китап төпләү, язу, аны бастырып чыгару бик зур көч, акыл, талант, тырышлык таләп итә. Кайберәүләр каяндыр могҗиза көтәләр, ә кулларында, китап тартмаларында яткан могҗизаны күрмиләр.

Китаплар вакытка буйсынмыйлар, алар мәңгелек. Алар безне үткәнгә, бүгенге дөньяга һәм киләчәккә сәяхәт иттерәләр. Китапның битләре, хәрефләре, рәсемнәре юкка чыгарга, тузарга мөмкин, ә эчтәлеге халык күңелендә сакланыр. Бәлкем, аның авторы да, исеме дә онытылыр, ә асылы кеше күңелендә яшәр.

Китапны теләсә кайсы вакытта ачып укырга була, бернинди чикләр дә юк. Кайберәүләр китапларны интернет алыштыра, диләр. Мин мондый фикер белән һич тә килешә алмыйм, чөнки иске дус (китаплар) яңа дустан (интернеттан) яхшырак. Тылсымлы көчкә ия китаплар хәреф танымаган сабыйларны да үзләренә чакырып, ымсындырып торалар. Шул могҗизаны саклыйк, яратыйк.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.